ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 31 Иске Урыссу ав. 28 декабрь 2018 ел

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә һәм муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 13 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 28 декабрендәге «Иминият пенсияләре турында»гы 400-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә һәм муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 13 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә "иминият пенсияләре турында" Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәч яки картлык буенча иминият пенсиясен вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәндә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.ел.».

1.2. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru Ютазы муниципаль

районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: www.jutaza.tatar.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Ф.Г. Әминова